# *Хат*



**Кояшның шаян нурлары**
**Безне уята.**
**Хәерле иртә тели ул,**
**Хәерле иртә!**
**Син дә шулай һәркемгә**
**Елмаеп эндәш.**
**Бәхет, шатлык, куаныч**
**Булсын гел юлдаш!**

**Чын дус нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?**

*Дус*

*Ярдәмчел, игътибарлы*


*Булыша, коткара, ярдәмга ашыга*

*Иң якын сердәшем*

*Иптәш*

Теле юк, теләсә кем белән сөйләшә,

Гәүдәсе юк, кәгазьдән күлмәк кия.



Аягы юк – китәр,

Җибәргән җиргә җитәр,

Кушкан йомышны үтәр.



Дүрт почмаклы келәтем,

Аккошым бар эчендә;

Кеше алыр дип кайгым юк,

Тамгасы бар түшендә.



**Сүзлек өстендә эш:**

**хат**- письмо

**аралашу чарасы** - средство общения

**мәгълүмат алмашу** - обмен информации

**төп өлеше** - основная часть

**ахыры** - конец

**хәбәр итү** – сообщение

**вакыйгалар** - события

**очраклар** - случаи

Сез ничек уйлыйсыз, хат нәрсә ул?



**Хат** – эш кәгазе, аралашу чарасы һәм мәгълүмат алмашуның киң таралган юлы. Почта аша җибәрелә.

**Письмо**-текст на бумаге или других материалах, используемый при переписке между двумя и более адресатами.



Рәсми хатлар – официальные письма



Шәхси хатлар – личные письма

Мәхәббәт хатлары – любовные письма




Дуслык хатлары – дружеские письма


Көтеп алынган хатлар – долгожданные письма

Җавап хаты – ответное письмо

Фронт хатлары – фронтовые письма

Электрон хатлар – электронные письма






Хат
башы
информация
ахыры
исәнлә шү
хәл сорашу
мин нишләд ем
минем планна рым
саубулла шу
хат язучы турынд а информ ация

Сәлам Казаннан!

Исәнме, якын һәм кадерле дустым Алсу!



Сиңа сәлам белән дустың Артем хат яза.



Әтиеңә, әниеңә, абыеңа, әбиеңә дусларыңа миннән сәлам әйт.

Алсу, мин синең хатыңны алдым, бик зур рәхмәт. Хатың бик кызыклы, мин аны рәхәтләнеп укыдым.

Алсу, синең хәлләрең ничек? Авырмыйсыңмы? Ничек укыйсың?

Нинди яңалыклар бар? Әтиең, әниең исән-саумы? Шулар турында хат яз, көтәм.

Сәлам белән, дустың Артем.

15 нче март, 2016 нчы ел

**Сәлам Казаннан!**

Исәнме, якын һәм кадерле дустым Алсу! Сиңа сәлам белән дустың Артем хат яза. Әти-әниеңә, апаңа, дусларыңа, Сашага миннән сәлам әйт.

Алсу, мин синең хатыңны алдым, бик зур рәхмәт сиңа! Хатың бик кызыклы, мин аны рәхәтләнеп укыдым.

Мин дә спортны яратам. Миңа йөзү, чаңгыда шуу, волейбол, баскетбол уйнау бик ошый. Ике ел волейбол секциясенә йөрдем. Безнең мәктәпнең волейбол командасы шәһәр буенча икенче урынны алды. Бу – безнең өчен зур уңыш, әлбәттә.

Алсу, синең хәлләрең ничек? Авырмыйсыңмы? Ничек укыйсың? Нинди яңалыклар бар? Әтиең, әниең исән-саумы? Шулар турында хат яз, көтәм.

Сәлам белән дустың Артем
15 нче март, 2017 нче ел

**ХАТ**

**Эчтәлекле, аңлаешлы**

**Кызыксындыра, таныштыра, үрнәк алдырта**

**Хат язышу – бик кызыклы шөгыль ул.**

**Өй эше**

1. Үз тормышыгызда булган 1-2 вакыйга турында әйтеп туганыгызга хат язарга.
2. Үзең язган хатны өйрәнергә.
3 Хатның башын, ахырын өйрәнергә.

# Сау булыгыз, укучылар!

